Башҡортостан Республикасы Мәгариф Министрлыгы
балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет
учреждениясы Уфа районы балалар иҗат йорты

# Тикшеренү эше

## *“Авылыбыз чишмәләре”*

Эшне башҡарды:

«Дуслык» фольклор студиясы.

Җитәкчесе:

Ғиндуллина Гөлфинә Нуррахман кызы
югары квалификациялы педагог.

Уфа -2015

**Әчтәлеге**

**I Кереш**

**Табигать күрке-чишмәләр**

**II Авылыбыз чишмәләре**

**Хәтер чишмәсенең атамасы, килеп чыгу тарихы.**

**III Йомгаклау**

**IV Файдаланылган әдәбият**

## Табигать күрке-чишмәләр

Чишмәләр-тереклек чыганагы,җир куенының җиденче катламнары аша бәреп чыгучы саф су. Зур дәрьяләр,Димнәр,
Агыйделләр үзләрнең мул сулары белән чишмәләргә бурычлы бит .Һәр елга башы –чишмә. Алар безнең рухыбыз. Чишмәләрне халык гомер-гомергә яраткан, кичке уеннар су буенда үткән, гашыйк парлар чишмә буенда вәгъдәләр бирешкән. Көянтә чиләк белән су буена төшкән кызларны егетләр күзләгән. Һәр авылның иң хөрмәтле, иҗтиһатлы картлары чишмәләрне карап, барлап торганнар, кизләүләргә кибәргә ирек бирмәгәннәр.

Чишмәне савыктыру, иң башлап, күңелләребезне савыктыру ул. Чөнки чишмә – су чыганагы гына түгел, рухыбыз көзгесе. Чишмә суларыбыз алдагы буыннарга, аларны яңартучыларның рух җылысын алып барыр. Көмеш агымнар авыруларны сихәтләндерер, хезмәт кешесенә көч-куәт бирер, милләтнең рухын ныгытыр.
Гасырлардан гасырларга чишмә безнең халык өчен илһам чыганагы булган. Ул җырларда туган як белән тәңгәл куела.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.
(Г.Тукай "Туган авылым”)

Җир – Анабыз биргән иң зур байлыкларның берсе – ул эчәр суыбыз. Ә эчәр су дигәндә,без инде, иң беренче итеп, өянкеләр күләгәсеннән бәреп чыккан саф чишмәләребезне күздә тотабыз. Чишмә булган җирдә яшеллек тә, сайрар кошлар да, аерым бер ямь дә була. Су, һава, җир – бер чылбыр. Шуларның берсе генә сау булмаса да, кеше үзе сәламәт була алмый. Чишмә челтерәгәнен тыңласаң - колакларың изри, бер йотым салкын суын эчсәң, җаның сихәтләнә.

Борынгы кешеләр чишмә, кое, диңгез, елга, күл, буа, кебек су чыганакларына табынганнар .Аларны изге әйберләр дип исәпләгәннәр. “Чишмә не пычратма, кулыңны чуан басар”,-дигәннәр борыңгылар.

Чишмә-чисталык сафлык пакьлек билгесе.Гадел, киң күңелле ,эчкерсез кешәләрне чишмә суының сафлыгына тиңлиләр.Чишмә суы тылсымлы көчкә ия, шуңа күрә борынгыдан изге чишмәләр, шифа чишмәләре турында легендалар,мифлар яши.

Соңгы елларда сулыкларны, бигрәк тә чишмәләрне төзекләндерүгә тәртипкә кертүгә игътибар артса да, сулыкларның пычрануы, ярларыбызның җимерелүе, чишмә башларыбызның томалануы күңелне борчый.Мөхитне

берөзлексез пычратып тору экологик халәтнең бозылуына, табигатьнең зарарлануына китерә.Кеше үзенең ваемсызлыгы белән Җир йөзендәге бар тереклекне, шул исәптән үзен дә юкка чыгарырга мөмкин.Без бу турыда бик якшы белергә тиешбез һәм онытырга хакыбыз юк.

Югарыда әйтелеп үткән проблема бүгенге көнне бик актуаль.һәм быелгы Республика күләмендә игълан ителгән "Башкортостан энҗеләре"фестиваль-конкурсына әзерлек өчен бирелгән тема(елга-суларга сакчыл караш) авылыбыз чишмәләренә карата бездә зур кызыксыну уятты һәм авылыбыз чишмәләре турында тикшеренеү эшен башларга этәргеч булды.

**Максат.**

Авылыбызның чишмәләрен барлау һәм аларга карата халыкның игътибарын юнәлдерү.

**Бурычлар.**

-чишмәләр турында мәгълүмәт туплау
-әһәмиятен аңлату
-исемнәре һәм тарихлары белән кызык сыну
-чишмәләрне торгызу эшенә өлкәннәрне этәрү
-чишмәләргә бәйле милли гореф-гадәтләребез белән кызыксыну уяту

**Төп тикшереү предметы.**

Авылыбыз чишмәләре

**Тикшереү методлары.**

-сораштырулар үткәрү
-өлкән буын вәкилләре белән очрашулар үткәрү
-халык алдында чишмәләр турынды төрле чаралар, чыгышлар әзерләп күрсәтү
-чишмәләр турында әдәбият уку
-мәктәбебездә эшләп килгән экологлар группасы белән очрашу оештыру

**Практикада кулланышы.**

-география дәрәсәлләренә,экологолар түгәрәкләре өчен ярдәмчел кулланма
-мәктәбебез музее өчен чишмәләребез тарихы турында мәгълүмәт

# Авылыбыз чишмәләре

Һәр авылда диярлек чишмәләр бар, гадәттә , алар кемнеңдер исеме белән атала,ниндидер тарихы була.Чишмә исеме аны казып чыгарган,гомер буена чистарып ,тәртиптә тоткан кешеләрнең истәлегенә атала.Сәфәрдә йөргәндә матур итеп киртәләп алынган ,шифалы салкын суны савытларга тутырыр, юыныр өчен уңайлы итеп улагы эшләнгән, ял итәр өчен эскәмияләр куелган чишмә янында туктап хәл алу үзе бер рәхәтлек ,ләззәт бирүче мизгелләр.

Халыкның килеп төпләүне дә нәкъ суга,чишмәләрнең бырлыгына бәйле.Сузыз җиргә берәү дә килеп утырмаган .

Без яшәгән Нөрле авылы да суларга бай һәм чишмәләре дә кайчандыр чылтрап агып утрыган.Авыл картлары белән очрашып сөйләшкәч авылыбызда өч ташаландык чишмә барлыгын белдек.Берсе авылдан төн-яктарак,бер чакырым чамасы ераклыкта, урман эчендә урнашкан.Шуңа күрә “Урман” чишмәсе дип атала.Бу чишмә турында экологлар группасы җитәкчесе Гөлфия Валиханова менә нәрсәләр сөйләде.

“Бу чишмә турында без авыл халкыннан ишеттек.Печән чабучылар, утын кисүчеләр, көтүчеләр ул челтерәп агып яткан чишмәнең иң якын дуслары булып чыктылар.Алар бу чишмә суының тәмле,чиста,салкын булуын әйттеләр.Чишмә авылыбызның “Колхозка” елгасына агып төшә икән. Һәм без балалар белән барып күрергә булдык. Чишмә үзенә иң матур урынны сайлаган.Сазлыкларда үсә торган бөтен төр үләннәр уратып алган үзен.Агып чыга торган башында шомырт, тал агачлары үсеп утыра.Иртә яздан,тирән көзгә кадәр без ул чишмәгә барып йөрдек.Төшкән агач ботыкларыннан арындырдык,чүп-чарлардан тазарттык.Оста куллы малайлар, шунда үсеп утырган талларны кисеп,шулардан читән үреп чишмәне уратып алдылар.Соңыдан суының составын тикшердек.Салкын, тәмле булуы белән бергә ул төрле микроэлементларга да бай булып чыкты”

Бу кызыклы әңгәмәдән соң, яз җитү белән, “Урман” чишмәсен бергәлешеп барып күрергә сүз куештык.

Авылның көнягындарак,шулай ук бер чакрым чамасы ераклыкта, “Сухарау” елгасы буенда ,тагын бер чишмә барлыгын белдек. Балыкчыларны,көтүчеләрне,гөмүмән шул якка йөрүче юлчаларны хезмәтләндерә икән.

“Шушы авылда 78ел гөмер итәм.Үземне белә башлаганнан бирле шушы чишмәнең барлыгын беләм-дип башлады үзенең сүзен Фатыхова Гөлсем әби.Бәләкәйдән балык тотып,көтү көтеп ,шул чишмә буенда куыш корып, суыннан авыз итеп үтте гомер.Менә шушы чшмә суының тәме әле дә авызымнан китми.Шул тиклем тәмле була торган иде.Кайтышлый чәй  суына дип ,савытларга тутырып алып кайта идек.Чишмә кырыен уратып алган ташлары җимерелеп, чыга торган урынын ком капласа, әтием шул ташалрны матур итеп тезә торган иде.Ә миңа комнарын тазартырга куша иде.Тирә ягында чүп-чар калдырсалар  шуларны җыеп тиргәнә,тиргәнә яндыра иде. Көтүчеләр әле дә чишмәне карап тазартып торалар торуын.Тик менә шул чишмә буен матурлап,әйләндереп алып ,караучы юк инде.”

Бу чишмәнең исеме юк.Сухарау елгасы буенда урншканга күрә,сухарау буендагы чишмә дип кенә йөртәләр.Ә без чишмәгә исем куштык. “Ялан” чишмәсе дип атадык.Һәм чишмәкәй ихтирамга,игътибарга лаек икәнен аңладык.Һәм башкаларда да кызыксынү уятырбыз дип ышанып калабыз. Шулай булганда “Ялан” чишмәсе ятим, ташландык булмас.

А менә авылны икегә бүлеп агып яткан өченче ,Колхозка елгасы буендагы” Хәтер” чишмәсе ,безне бигрәк тә кызык сындырды,дулкынландырды.Исемен ишетү белән, Хәтер исемле кеше дә була икән дип уйладык.Чөнки чишмәләр гадәттә кеше исеме белән аталалар.Баксак, бу чишмәнең исеме тарихына, тарихы исеменә бик тап килеп тора икән.Чишмә ташланган,каралманган булса да авылының аксакаллары аның урынын да, тарихын да, исеменең килеп чыгышын да бик яхшы хәтерлиләр.

“Аның тарихы бераз моңсу,-дип башлады 92 яшлек Шәфига әби. Чишмә буе яшьләрнең бердән бер күңел ача торган урыны иде.Кичке уеннар шушы чишмә буенда үтә иде.Сугыш башлангач, безнең авылның  ир-егетләре дә чакыру кәгазлары алды.Озатканда шушы чишмә буена җыелдылар.Кичке уенга түгел,әлбәттә. «Ризыкларыбыз бетмәсен чишмәкәй,дошманны җинеп , исән-имин әйләнеп кайтырга язсын»-дип теләкләр теләп, суыннан авыз иттеләр,тәңкәләр салдылар.Чишмәкәйне тазартып, фатихалар кылып,телеәкләрне янартып торган авыл халкы,чишмә агуыннан туктамаса, киткән ир-егетләребез әйләнеп кайтыр дип ,өмет иттеләр.Никадәр өметләнеп көтсәләр дә күбесе яу кырларында ятып калды.Ә чишмәкәй хәтерләрне яңартып акты да, акты.Менә “Хәтер” атамасы да шуннан аның.

Шәфига әби сөйләве күңелләргә шул тиклем үтеп керде.Без үзебез язган сценканы шушы чишмәгә багашладык.Һәм “Батырларын чишмә онытмый” дип атадык.Сценарии буенча Хәтер чишмәсенә җаң өрдек, тазартык, матурладык,авыл халкы алдында чыгыш ясадык.Һәм үзебезне дә,авыл халкын да чын барлыкта да шулай булачагына ышандырду иде максатыбыз.



Хәтер чишмәсе турында 92 яшлек Шафига әби сөйли.




8-нче класс укучысы Фатыхов Радмир Фатыхова Гөлсем әби белән Сухарау буендагы чишмә турында әнгәмәләшә.







Экологлар җитәкчесе-Валиахметова Гөлфия белән очрашканнан соң

Урман чишмәсе турында әңгәмә






**Киләчәктә авылыбызнын  чишмәләрен менә шулай күз алдыбызга китерәбез. Һичшиксез шулай булуына ышанабыз.**

# Йомгаклау

Чишмәләр-сафлык,паклык символы.Аларны тәртиптә тоту, тазарту, саклау,кадерен белү һәр кемнең изге бурычы.Без чишмәләрнең шифалы, тәнебезгә көч дәрт бирүенә ышанабыз һәм чишмә суларына карата күңелебез дә хөрмәт сүңгәне дә юк.Бу тема өстендә эшләү, бу проблеманы күтәреп чыгу бездә һәм авыл халкында чишмәләргә карата зур кызык сыну уятты.Авылыбыз чишмәләренең барлыгын белдек һәм күрдек.Авыл халкы белән сөйләшеп күп мәгълүмәт җыйдык.Киләчәктә чишмә суларына карата сакчыл караш ,алрны тазартау, матурлау,төзекләндереү,кебек изге гамәлләр кылып яшәргә иде дигән теләкләр уянды күңелләрдә.

Авыл аксакалларының чишмәләр турында әйтелгән акыллы сүзләре һәр беребезнең хәтерендә сакланыр.Чишмә суын алганда менә нәрсәләрне истә тотырга кирәк икән.

- чишмә суын салкынча урында сакласан яхшырак була
-су алганда тыныч кына ,изге уйлар уйла
-иртән алган су,кичке суга караганда файдалырак
-төнлә су алырга ярамай
-берюлы 9 чишмәнең суын алып кушсан,шифасы көчлерәк була.

Чишмә-суларга карата сакчыл караш олы мирас булып буыннан буынга тапшырылсын иде.Табигатьне саклау безенең изге бурычыбыз.Без бу хакта яхшы беләбез һәм онытырга хакыбыз юк.

# Файдаланылган әдәбият

1.Балалар фольклоры .1-че китап. Бала чак-уйнап –көлеп үсер чак. Уфа,1994

2.Башкирская мифология для школьника. Уфа,2012.

3.Җырлап ачыла күңел.Җырлар һәм көйләр.Казан,1993.

4.Могҗизалы мәктәп сәхнәсе.Балар бакчалары тәрбиячеләре,сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек.Казан,2003.

5.Коробкин В.И., Передельский Л.В. «Экология», издательство «Мир» 2000г

6. Плотников Н. И. Подземные воды – наше богатство. М. «Недра». 1990. 204с.